КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 сентябрь г.Казань № 773

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 20 июль, 605 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 10 июнь, 543 нче; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче; 2023 ел, 3 июль, 779 нчы; 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче; 2023 ел, 15 декабрь, 1621 нче; 2024 ел, 28 март, 192 нче; 2024 ел, 6 июнь, 409 нчы; 2024 ел, 12 сентябрь, 765 нче; 2025 ел, 19 апрель, 251 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладлары күләме, сум |
|---|---|---|
| «Социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы икенче дәрәҗә белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча техник | 29 700 |
| | Социаль хезмәткәр | |
| «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә һәм социаль хезмәтләр күрсәтелә торган учреждениеләрдә өченче дәрәҗә белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Инвалидларга һөнәри юнәлеш бирү буенча белгеч | 33 940 |
| | Социаль эшләр буенча белгеч | |
| | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методист | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Медицина психологы | 35 750 |
| | Инвалидларны тернәкләндерү буенча белгеч | |
| | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча инженер | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Инвалидларны һөнәри тернәкләндерү буенча консультант | 36 250 |
| «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә һәм социаль хезмәтләр күрсәтелә торган учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Бүлек (социаль хезмәт) мөдире | 36 470 |

«Гаилә белән эшләү буенча белгеч» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрнең база оклады 33 940 сум күләмендә билгеләнә.

«Комплекслы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог)», «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрнең база окладры – 35 750 сум.

2.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладры күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче ярдәмчесе | 25 960 |
| Икенче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 26 090 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | 27 390 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Инструктор-методист | 27 500 |
| | Концертмейстер | |
| | Социаль педагог | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 27 650 |
| | Методист | |
| | Педагог-психолог | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән тәрбияче | 27 780 |
| | Өлкән методист | |
| | Укытучы | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |

Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларның, акылга зәгыйфьләр өчен балалар интернат йортларының педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла.

Тармак өстенлеге коэффициентының күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрендәге беренче – өченче квалификация дәрәҗәләре хезмәткәрләре өчен – 1,4;

педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрендәге дүртенче квалификация дәрәҗәсе хезмәткәрләре өчен – 1,5.

Мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла.

Тармак өстенлеге коэффициентының күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрендәге беренче – өченче квалификация дәрәҗәләре хезмәткәрләре өчен – 1,34;

педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрендәге дүртенче квалификация дәрәҗәсе хезмәткәрләре өчен – 1,44.

Әлеге коэффициентларны база окладына карата куллану яңа база окладын (арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләп) барлыкка китерә, компенсация һәм стимуллау характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.

2.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм фәнни хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече фәнни хезмәткәр | 34 380 |
| | Фәнни хезмәткәр | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән фәнни хезмәткәр | 35 260 |

2.4. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация | Санитар (санитар хатын-кыз) | 25 650 |
| | Авыруларны карау буенча кече шәфкать | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| дәрәҗәсе | туташы (авыруларны карау буенча кече медицина браты) | |
| | Хуҗалык эшләре буенча хезмәткәр | |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 26 660 |
| | Хезмәт терапиясе буенча инструктор | |
| | Стерилизация буенча шәфкать туташы (стерилизация буенча медицина браты) | |
| | Медицина дезинфекторы | |
| | Медицина регистраторы | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы буенча табиб (туклану гигиенасы буенча табиб, хезмәт гигиенасы буенча табиб, гигиена тәрбиясе буенча табиб, коммуналь гигиена буенча табиб, гомуми гигиена буенча табиб, табиб-паразитолог, радиация гигиенасы буенча табиб, табиб-эпидемиолог) ярдәмчесе | 27 210 |
| | Диета буенча шәфкать туташы (диета буенча медицина браты) | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина браты) | 27 760 |
| | Палата (пост) шәфкать туташы (палата (пост) медицина браты) | |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы (физиотерапия буенча медицина браты) | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина браты) | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Акушер (акушер хатын-кыз) | 28 530 |
| | Фельдшер | |
| | Процедура шәфкать туташы (процедура медицина браты) | |
| | Бәйләү бүлмәсенең шәфкать туташы (бәйләү бүлмәсенең медицина браты) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина браты), өлкән акушер (өлкән акушер хатын-кыз), өлкән фельдшер, өлкән операция шәфкать туташы (өлкән операция медицина браты), өлкән теш техникы | 29 630 |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 32 090 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми практика табиблары (гаилә табиблары) (дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 33 060 |
| «Учреждениеләрдә структур бүлекчәләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарларның хирургия профилендәге бүлекләр мөдирләреннән башка) | 36 470 |

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең кайбер вазыйфалары өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициентлары кулланыла.

Тармак өстенлеге коэффициентының күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

«Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеменә керә торган вазыйфалар буенча – 1,2;

«Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеменә керә торган вазыйфалар буенча – 1,25;

«Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеменә керә торган вазыйфалар буенча – 1,3;

«Учреждениеләрнең структур бүлекчәләрендә югары медицина һәм фармацевтика белемле җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)» һөнәри квалификация төркеменә керә торган вазыйфалар буенча – 1,3.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген, куелган бурычларны үтәгәндә мөстәкыйльлек һәм җаваплылык дәрәҗәсен исәпкә алып, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең кайбер вазыйфалары өчен база окладына карата арттыру коэффициентлары кулланыла:

«хуҗалык эшләре буенча хезмәткәр» вазыйфасы буенча – 1,05;

кайбер дәүләт медицина оешмаларының бишенче квалификация дәрәҗәсендәге «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме буенча – 1,1.

Әлеге коэффициентларны база окладына карата куллану яңа база окладын (арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләп) барлыкка китерә, компенсация һәм стимуллау характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.

2.5. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча инструктор-методист | 26 610 |

2.6. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | 1 айга база окладары күләме, сум |
|---|---|
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Мәдәни чаралар оештыручы | 27 450 |
| Аккомпаниатор | |
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 28 000»; |

25 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемен характерлый торган күләм күрсәткечләре, җитәкчеләренең база һәм вазыйфа окладлары

| Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре типлары, җитәкченең хезмәт өчен түләү төркеме | Күрсәткеч исеме (зурлыгы) | База окла-ды, сум | Җитәкчеләрнең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент зурлыгы | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар | койка-урыннар саны | | | |
| I | 51 һәм аннан да күбрәк | 66 550 | 1 | 66 550 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| II | 31 – 50 | 66 550 | 0,9 | 59 895 |
| III | 16 – 30 | 66 550 | 0,85 | 56 568 |
| IV | 15 кә кадәр | 66 550 | 0,75 | 49 913 |
| Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләре | койка-урыннар саны | | | |
| I | 51 һәм аннан да күбрәк | 59 290 | 1 | 59 290 |
| II | 31 – 50 | 59 290 | 0,9 | 53 361 |
| III | 16 – 30 | 59 290 | 0,75 | 44 468 |
| IV | 15 кә кадәр | 59 290 | 0,7 | 41 503 |
| Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йортлары, физик кимчелекләре булган балалар өчен балалар интернат йортлары | койка-урыннар саны | | | |
| I | 100 дән артык | 66 550 | 1 | 66 550 |
| II | 80 – 100 | 66 550 | 0,95 | 63 223 |
| III | 50 – 80 | 66 550 | 0,85 | 56 568 |
| IV | 50 кә кадәр | 66 550 | 0,75 | 49 913 |
| Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлар | койка-урыннар саны | | | |
| I | 501 һәм аннан да күбрәк | 67 760 | 1 | 67 760 |
| II | 401 – 500 | 67 760 | 0,95 | 64 372 |
| III | 301 – 400 | 67 760 | 0,9 | 60 984 |
| IV | 300 кә кадәр | 67 760 | 0,85 | 57 596 |
| Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат йортлар (пансионатлар) | койка-урыннар саны | | | |
| I | 151 һәм аннан да күбрәк | 53 850 | 1 | 53 850 |
| II | 101 – 150 | 53 850 | 0,95 | 51 158 |
| III | 50 – 100 | 53 850 | 0,82 | 44 157 |
| IV | 50 кә кадәр | 53 850 | 0,72 | 38 772 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр, гаиләгә һәм балаларга ярдәм үзәкләре | штат берәмлекләре саны | | | |
| I | 301 һәм аннан да күбрәк | 68 970 | 1 | 68 970 |
| II | 150 – 300 | 68 970 | 0,95 | 65 522 |
| III | 100 – 149 | 68 970 | 0,7 | 48 279 |
| IV | 51 – 99 | 68 970 | 0,65 | 44 831 |
| V | 50 кә кадәр | 68 970 | 0,62 | 42 761 |
| Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге | койка-урыннар саны | | | |
| I | 91 һәм аннан да күбрәк | 53 240 | 1 | 53 240 |
| II | 51 – 90 | 53 240 | 0,9 | 47 916 |
| III | 15 – 50 | 53 240 | 0,8 | 42 592 |
| IV | 15 кә кадәр | 53 240 | 0,75 | 39 930 |
| Инвалидларны тернәкләндерү үзәге | койка-урыннар саны | | | |
| I | 100 һәм аннан да күбрәк | 52 030 | 1 | 52 030 |
| II | 51 – 99 | 52 030 | 0,9 | 46 827 |
| III | 15 – 50 | 52 030 | 0,85 | 44 226 |
| IV | 15 кә кадәр | 52 030 | 0,75 | 39 023 |
| Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен социаль тернәкләндерү үзәге | | | | |
| I | | 39 930 | 1 | 39 930 |
| «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе | | | | |
| I | | 77 440 | 1 | 77 440 |
| «Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе | | | | |
| I | | 71 390 | 1 | 71 390»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладын билгеләү

2.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база окладында күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 010 |

2.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база окладында күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 26 660 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 26 870 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 27 080 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 27 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 27 560 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 780 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 28 000 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 29 040 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 29 260 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 29 480 |

2.3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кертелмәгән хезмәткәрләр вазыйфаларындагы хезмәткәрләргә база окладлары күләмнәре бу Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә хезмәтнең катлаулыгына карап билгеләнә.

2.4. Берьюлы ике эш урынында, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменә бәйле рәвештә башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы ике эш урынында эшләү тәртибендә биләгән вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла.»;

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кертелмәгән хезмәткәрләр вазыйфалары буенча хезмәткәрләрнең база окладлары

| Һөнәри стандартлар буенча вазыйфа исеме | Белемгә һәм практик эш тәҗрибәсенә карата таләпләр | Һөнәри стандартлар буенча вазыйфага карата һөнәри квалификация төркемнәре вазыйфасы исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Мәгълүмат коммуникацияләре технологияләре бүлегенең кече белгече;<br>мәгълүмат коммуникацияләре технологияләре бүлеге менеджеры;<br>кече система администраторы | урта һөнәри белем – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары;<br>эш стажы – мәгълүмат коммуникацияләре системалары җайланмаларын техник тәэмин итү, алар белән идарә итү, аларны программалаштыру өлкәсендә кимендә өч ай эшләү | техник | 26 030 |
| Система техникы;<br>кече система администраторы | урта һөнәри белем – урта звено белгечләрен әзерләү программалары;<br>өстәмә һөнәри белем – компьютер һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары; | 2 категорияле техник | 26 220 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | эш стажы – мәгълүмат коммуникацияләре системалары җайланмаларын техник тәэмин итү, алар белән идарә итү, аларны программалаштыру өлкәсендә кимендә өч ай эшләү | | |
| Система администраторы; белгеч; инженер | югары белем – бакалавриат программалары яки урта һөнәри белем – урта звено белгечләрен әзерләү программалары; өстәмә һөнәри белем – компьютер һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары; эш стажы – урта һөнәри (техник) белем булганда мәгълүмат коммуникацияләре системалары җайланмаларын техник тәэмин итү, алар белән идарә итү, программалаштыру өлкәсендә кимендә бер ел эшләү | инженер-программист (программист) | 27 080 |
| Система инженеры; система администраторы | югары белем – бакалавриат программалары яки урта һөнәри белем – урта звено белгечләрен әзерләү программалары; өстәмә һөнәри белем – компьютер һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә квалификация күтәрү программалары, һөнәри | 2 категорияле инженер-программист (программист) | 27 300 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | яңадан әзерләү программалары | | |
| Мәгълүматлар базалары администраторы; система администраторы | югары белем – специалитет программалары, магистратура программалары | 1 категорияле инженер-программист (программист) | 27 560 |
| Әйдәүче белгеч; әйдәүче система инженеры; өлкән система администраторы | югары белем – специалитет программалары, магистратура программалары; өстәмә һөнәри белем – компьютер һәм телекоммуникация системалары һәм чаралары өлкәсендә квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары; эш стажы – система белән идарә итү өлкәсендә кимендә алты ай эшләү | әйдәүче инженер-программист (программист) | 27 780 |
| Әйдәүче система администраторы; баш система администраторы | югары белем – специалитет программалары, магистратура программалары; өстәмә һөнәри белем – компьютер һәм телекоммуникация системалары һәм чаралары өлкәсендә квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары; эш стажы – система белән идарә итү өлкәсендә кимендә алты ай эшләү | баш белгеч | 28 000 |
| Сатып алулар буенча белгеч; контракт хезмәте | урта һөнәри белем; өстәмә һөнәри белем – сатып алулар өлкәсендә | бухгалтер; икътисадчы; юрисконсульт | 27 080 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| хезмәткәре; контракт белән идарә итүче | квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары | | |
| Сатып алулар буенча өлкән белгеч; сатып алулар буенча консультант; контракт хезмәте хезмәткәре; контракт белән идарә итүче | югары белем – бакалавриат программалары; өстәмә һөнәри белем – сатып алулар өлкәсендә квалификация күтәрү программалары яки һөнәри яңадан әзерләү программалары; эш стажы – сатып алулар өлкәсендә кимендә өч ел | 1 категорияле бухгалтер; 1 категорияле икътисадчы; юрисконсульт 1 категория | 27 560 |
| Әйдәүче белгеч; контракт хезмәте хезмәткәре; бүлекчә җитәкчесе урынбасары; бүлекчә җитәкчесе; контракт буенча хезмәт җитәкчесе; контракт белән идарә итүче | югары белем – специалитет программалары, магистратура программалары; өстәмә һөнәри белем – сатып алулар өлкәсендә квалификация күтәрү программалары яки һөнәри яңадан әзерләү программалары; эш стажы – сатып алулар өлкәсендә кимендә өч ел | әйдәүче бухгалтер; әйдәүче икътисадчы; әйдәүче юрисконсульт | 27 780 |
| Кадрлар эшен башкару буенча белгеч; персоналга бәйле эшләрне документлар белән тәэмин итү буенча белгеч; персоналны документлар белән тәэмин итү буенча белгеч; персонал буенча белгеч | урта һөнәри белем – урта звено белгечләрен әзерләү программасы; өстәмә һөнәри белем – һөнәри яңадан әзерләү программалары, квалификация күтәрү программалары | кадрлар буенча инспектор | 26 030 |
| Персонал сайлау буенча белгеч; персонал буенча | югары белем – бакалавриат программалары; өстәмә һөнәри белем – | кадрлар буенча белгеч; персонал буенча менеджер | 27 080 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| белгеч | персонал эзләү һәм сайлау өлкәсендә квалификация күтәрү программалары яки һөнәри яңадан әзерләү программалары | | |
| Персоналны бәяләү һәм аттестацияләү буенча белгеч; персонал буенча белгеч | югары белем – бакалавриат программалары; өстәмә һөнәри белем – персоналны бәяләү өлкәсендә квалификация күтәрү программалары яки һөнәри яңадан әзерләү программалары | персонал буенча 2 категорияле менеджер | 27 300 |
| Персоналны үстерү һәм укыту буенча белгеч; персонал карьерасын үстерү буенча белгеч; персонал буенча белгеч | югары белем; өстәмә һөнәри белем – персоналны оештыру һәм һөнәр ягыннан үстерү өлкәсендә квалификация күтәрү программалары яки һөнәри яңадан әзерләү программалары | персонал буенча 1 категорияле менеджер | 27 560 |
| Хезмәт нормасын билгеләү һәм хезмәт өчен түләү буенча белгеч; хезмәтне оештыру һәм хезмәт өчен түләү буенча белгеч; компенсацияләр һәм ташламалар буенча белгеч; персонал буенча белгеч | югары белем; өстәмә һөнәри белем – икътисад, хезмәт нормасын билгеләү һәм хезмәт өчен түләү өлкәсендә һөнәри яңадан әзерләү программалары, квалификация күтәрү программалары | персонал буенча әйдәүче менеджер | 27 780 |
| Административ-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итү буенча белгеч; офис-менеджер | урта һөнәри белем – урта звено белгечләрен әзерләү программасы; өстәмә һөнәри белем – эшчәнлек юнәлеше буенча һөнәри яңадан әзерләү программалары | склад мөдире; хуҗалык мөдире | 26 220 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Административ-хуҗалык бүлекчәсе җитәкчесе; административ-хуҗалык бүлекчәсе башлыгы | югары белем – бакалавриат; югары белем (профильгә карамаган) – бакалавриат; өстәмә һөнәри белем – эшчәнлек юнәлеше буенча һөнәри яңадан әзерләү программалары | хуҗалык бүлеге башлыгы | 26 420 |
| Карау буенча ярдәмче | һөнәри белем бирүнең төп программалары – хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары | бала караучы | 25 650 |
| Хезмәтне саклау буенча кече белгеч | урта һөнәри белем – хезмәтне саклау өлкәсендә урта звено белгечләрен әзерләү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү | хезмәт буенча техник | 25 650 |
| Хезмәтне саклау буенча белгеч | урта һөнәри белем – хезмәтне саклау өлкәсендә урта звено белгечләрен әзерләү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү; югары белем – бакалавриат яки югары белем (профильгә карамаган) – бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем – хезмәтне саклау өлкәсендә һөнәри яңадан әзерләү программалары; стажы – урта һөнәри белеме булганда хезмәтне саклау өлкәсендә кимендә өч ел | инженер; хезмәтне саклау буенча инженер | 27 080 |
| Хезмәтне саклау буенча баш (әйдәүче) белгеч | югары белем – бакалавриат яки югары белем (профильгә карамаган) – бакалавриат һәм | 1 категорияле инженер; хезмәтне саклау буенча 1 категорияле инженер | 27 560 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | өстәмә һөнәри белем – хезмәтне саклау өлкәсендә һөнәри яңадан әзерләү программалары; стажы – югары белеме булганда хезмәтне саклау өлкәсендә кимендә өч ел яки урта һөнәри белеме булганда хезмәтне саклау өлкәсендә кимендә дүрт ел | | |
| Гражданнар оборонасы буенча белгеч; гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча белгеч; гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча белгеч; гражданнарны саклау буенча белгеч | урта һөнәри белем – урта звено белгечләрен әзерләү программалары яки урта һөнәри белем (профильгә карамаган) – урта звено белгечләрен әзерләү программалары һәм өстәмә һөнәри белем – квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары | инженер | 27 080 |
| Гражданнар оборонасы буенча әйдәүче белгеч; гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча әйдәүче белгеч; гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча әйдәүче белгеч; гражданнарны саклау буенча әйдәүче белгеч | югары белем – бакалавриат яки югары белем (профильгә карамаган) – бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем – һөнәри яңадан әзерләү программалары | 2 категорияле инженер | 27 300 |
| Гражданнар оборонасы буенча баш белгеч; гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча | югары белем – бакалавриат яки югары белем (профильгә карамаган) – бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем – | 1 категорияле инженер | 27 560». |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| баш белгеч; гражданнар обороносы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча баш белгеч; гражданнарны саклау буенча баш белгеч | квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары; стажы – һөнәри эшчәнлек юнәлеше буенча кимендә өч ел | | |

2. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин